**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Ивашкино авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Ивашкино авыл җирлегенең Әккәрәй авылы**
**торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«08» ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 8 ноябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2020 елда Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең Әккәрәй авылы торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, ялгыз картлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәяүлеләр күперен ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, суга экспертиза һәм анализ өчен түләү;

- «Әккәрәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ өчен 50 метр койма сатып алу;
- «Ивашкино урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ өчен 30 метрлык керү юлын ремонтлауга төзелеш материаллары сатып алу;

ӘЙЕ ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 493 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 252 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 252 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлеге составына керүче Әккәрәй авылы торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: ««2020 елда Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең Ивашкино авылы торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, ялгыз картлардан һәм 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында җәяүлеләр күперен ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Ивашкино, Әккәрәй торак пунктларында скважиналарны лицензияләү, суга экспертиза һәм анализ өчен түләү;
- «Әккәрәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ өчен 50 метр койма сатып алу;
- «Ивашкино урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ өчен 30 метрлык керү юлын ремонтлауга төзелеш материаллары сатып алу;

карар кабул ителгән дип танырга.

1. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Әккәрәй авылы, Школьная ур., 28. Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ивашкино авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Ефимов